

Кеше тормышын агымсуга тинлиләр. Агымсулардай тиз аккан гомерне парлашып, бер-беренә терәк булып, кадерен белеп яшәсән, томыш матур була. Ходай сәламәтлек биреп, 60 ел ингә-ин гомер итv һәръяклап хөрмәткә, сокланугa лаек.
26 августта Алимовлар 60 ел бергә гомер итvләрен билгеләп vтәрләр.
Шәмил Каюм улы 1934нче елнын 20 ноябрендә Ләмберә районы Аксен авылында туа. Туган авылы мәктәбендә белем алганнан сон, 1953-55нче елларда, Казан технология техникумында техник профессиясен vзләштерә. Тозvче профессиясен жирдә эз калдыручылар профессиясе дип атар идем.      Шул ук вакытта, авыр һәм бик жаваплы эш. Шәмил Каюм улы озак еллар тозелештә мастер вазыйфасын vти. Ул тозvчеләр белән тиз уртак тел таба, житәкчеләреннән мактау сvзләре белән бергә торле грамоталар һәм бvләкләр ала. Шундый хормәтле профессия юлы vтә ул һәм бvген лаеклы ялда. Шәхси тормышына килгәндә - унган, тырыш кызны шул ук стройкада vзенә карата. Ул - Мяфруза була.
Мяфруза Ибраһим кызы Кадеева (кыз фамилиясе) 1937 елнын 19 октябрендә кvрше Татар Тавласы авылында туа. Хәтере яхшы булганлыктан, мәктәптә яхшы укый һәм хәзер дә кvп кенә шигырьләрне хәтерли. Кече яшеннән басуда әнисенә арыш урырга булыша, монын очен конենә ярты кило икмәк бирәләр. 1957нче елда тозелешкә каменьщица булып урнаша. Эшли дә, укый да ул. Кулында ут уйната, диләр бездә шундый осталарга. Бервакытта да эштән курыкмый ул. Шуна Мяфруза Ибраһим кызы, IV разрядлы оста хезмәткәр буларак,  кvпторле хормәтле бvләкләр ала. Лаеклы ялга Республикабыз балалар шифаханәсендә санитарка (1990-2000 елларда) булып китә. Бvген – кадерле тормыш иптәше, соекле әни, яраткан әнекай. Шәмил Каюм улы белән Мәфруза Ибраһим кызы бергәләп 4 бала тәрбияләр vстерәләр. Кvнел жылысын, йорәк дәртен, кайнарлыгын балаларына тулаем бирәләр Алимовлар. Шунадыр инде мәхәббәт жимешләренен дvртесе дә тәvфыйклы, тәрбияле булып vсә. Алар тырышлык, гадилек, тыйнаклыкны әти-әниләреннән кабул итеп ала. Тәнзиләләре - кырык елга якын Республика балалар больницасында шәфкать туташы-медсестра булып эшли. Гелсирәләре – Казанда торговля институтын тәмамлап, гомере буе шул профессиягә тугрылыклы булып яши. Ирфан уллары Саранск шәһәре автосервисларынын берсендә механик буларак хезмәт итә. Рифатлары, гаиләсе белән, Пенза шәһәрендә яши һәм хезмәт итә. Шәмил абый белән Мяфруза апа гомерләре буе хезмәттә хормәтле

булганнар, балаларын да тырыш профессия кешеләре буларак тәрбияләгәннәр. Гаилә - рух, миллилекне һәм мәдәниятны саклаучы учаг, буыннар чылбыры. Балалары корган гаиләләре дә кеше сокландырырлык. Бvген аларны Алсу белән Динара оныклары һәм Самир онықчыклары шатландыра. Менә шулай, бер-берсен анлап, хөрмәт итеп, Мордовия татарларында булган гореф-гадәтләрне, бәйрәмнәрне кадерләп, 60 ел бергә яшиләр Шәмил Каюм улы белән Мяфруза Ибраһим кызы Алимовлар.
60 ел! Шушы еллар эчендә тарихта нинди генә вакыйгалар булмаган. Ә бер гаилә эчендә?! Әтиебез утлы елларны кичкән, куркусыз кеше. Әниебезнен чисталыгына, пөхтәлегенә, кешелеклелегенә сокланырлык. Менә шундый сыйфатларга ия булган ике кеше, без дvрт балага гомер биреп, vз vрнәкләрендә безне тәрбияләделәр. Барысы очен дә без аларга мен-мен рәхмәтле! Алар бvген дә безгә бик кирәк. Алар булганда туган йортыбызнын нуры сvрелми, яшәv кочебез арта, һәм тормышыбызда әти-әниебез олы бер терәк. Озын һәм саулыклы гомерләр бирсен сезгә Аллаһы Тәгалә. Безгә дә әти-әни дип авыз тутырып дәшәргә бик кvп еллар насыйп итсен. Без бәхетле сез бар вакытта.

**Кадерле Әтиебез һәм Әниебез!**

Изге теләк, назлы сvздән башка табып булмый затлы бvләкне. Безнен очен бик тә кадерле сез, бик тә якын, бик тә кирәкле. Әни бит ул - ойнен жылысы, Әти – донья терәге. Әни белән әти бергә булса, тыныч була бала йорәге. Алтмыш ел бергә, инне-ингә куеп, бергә тартып тормыш арбасын, бер-берегезне соеп, безгә vрнәк булып, һәрчак туры юлдан барасыз. Шушы юлда юлдаш булсын сезгә безнен дә кайнар йорәк. Бала очен әти-әнидән башка беркем юк кадерлерәк!
Хөрмәт белән: сез vстергән балалар, гаиләгезгә кабул иткән кияv-киленнәр һәм балаларыгыздан да артык кvреп яраткан оныкларыгыз һәм оныкчыгыгыз.